ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл
җирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

**Карар**

«11» сентябрь 2020 ел № 138

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны факттагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль (соңгы үзгәрешләр белән) законның 52 статьясындагы 6 өлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексының 36 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Олы Мәңгәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны факттагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырылганнан соң үз көченә керә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Ф.К.Тахавиев

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2020 елның
«11» сентябрендәге 138 нче номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны факттагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларны акчалата тоту өчен факттагы чыгымнар турында квартал саен мәгълүматларның (алга таба - тәртип) халыкка җиткерүнең әлеге тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексының 36 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше нигезендә гамәлдәге редакциядә эшләнде һәм югарыда күрсәтелгән кварталлык белешмәләрне бирү, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларны тотуга факттагы чыгымнар турында мәгълүмат күрсәтелгән органнарның вәкаләтле затлары тарафыннан квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә бирелә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтле затлары бирелә торган мәгълүматның үз вакытында, дереслеге, аның Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисаплылыкка, башка рәсми хисаплылыкка туры килүе өчен шәхси җаваплылык тоталар.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җаваплы бүлекчәсе тарафыннан бирелгән мәгълүмат нигезендә хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең саны һәм аларның акчалата тоту өчен факттагы чыгымнары турында квартал саен әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә әзерләнә.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларны тоту өчен факттагы чыгымнар турында квартал саен Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосыннан да соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны фактагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның 20__ нчы елнын____квартал өчен акчалата тотуга фактагы чыгымнары турында**
**МӘГЪЛҮМАТ**

(ел башыннан бирле үсеп килүче нәтиҗә белән)

| Хезмәткәрләрнең категориясе | исемлек буенча уртача сан эшче саны | хисап чорында хезмәткәрләрнең эш хакына фактагы чыгымнары-мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре | | |